ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **03.03.2025 424** **КАРАР**

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләү бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 272-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының кадрлар потенциалын үстерүгә һәм педагогик кадрлар белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән муниципаль ярдәмне көчәйтү максатларында, Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләү бирү турындагы нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләүне бүлү комиссиясе турында нигезләмәне һәм комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләү бирү турындагы килешү формасын (рәвешен) 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне бирүгә бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән карауны тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.Е.Мерзонга йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0

Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна

Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 3 мартындагы
424 няе номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләү бирү турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга тиешле елда күрсәтелгән максатларга каралган Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары чикләрендә аларга ярдәм итү максатларында бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләү бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләү күләме һәр алучыга 400 000 (дүрт мең) сум күләмендә билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында түбәндәге шартлар җыелмасын үтәгән яшь педагоглар бер мәртәбә матди түләү алуга дәгъва кылучыларга түбәндәгеләр керә:

- Россия Федерациясе гражданнары булган;

-педагогик юнәлеш буенча югары яисә урта һөнәри уку йортын тәмамланганнан соң 3 ай дәвамында гомуми белем бирү оешмасына эшкә урнашкан;

- гомуми белем бирү оншмасына эшкә урнашу чоры 2022 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк вакытта булмаган;

- бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләүне алуга мөрәҗәгать итүченең гариза биргән вакытка педагогик стажы 3 елга тулмаган хезмәткәрләр;

- кимендә 1 ставкага эшләүче (атнага 18 сәгать) хезмәткәрләр;

- түләү алу өчен мөрәҗәгать итүченең гариза биргән вакытка 35 яше тулмаган хезмәткәрләр;

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне алмаган хезмәткәрләр;

- салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча үтәлмәгән бурычлары булмаган хезмәткәрләр.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

4. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алуга дәгъва кылучыларның гаризаларын карау эшен оештыру бүлү комиссиясенә йөкләнә ( алага таба-комиссия).

5. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кул куелганнан соң 10 эш көне эчендә нигезләмәне раслаучы «Алабуга муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә, әлеге нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән документларны җыю вакытын һәм комиссия утырышы датасын күздә тотып бер мәртәбә матди түләү алуга гаризалар җыя башлау турында хәбәр җибәрә (алга таба - хәбәрнамә).

Алдагы елларда хәбәрнамә агымдагы елның 15 сентябреннән дә соңга калмыйча җибәрелә «Алабуга муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә җиткерә.

6. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре хәбәрнамәдә билгеләнгән вакытка комиссиягә түбәндәге документларны юллыйлар:

1) яшь педагогның Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә бер мәртәбә матди түләү алуга гаризасы;

2) бер мәртәбә матди түләү алуга дәгъва кылучының шәхесен раслаучы документ күчермәсе;

3) бер мәртәбә матди түләү алуга дәгъвачы белеме турында диплом күчермәсе;

4) бер мәртәбә матди түләү алуга дәгъва кылучының шәхесен раслаучы документ күчермәсе;

5) эшкә алу турында боерык күчермәсе;

6) салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча үтәлмәгән бурычлары булмау хакындагы белешмәсе.

Документларның күчермәләре бер мәртәбә бирелә торган матди түләү алуга дәгъва кылучы эшли торган гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан таныкланырга тиеш.

7. Документлар алынган вакыттан комиссия әлеге нигезләмәнең 6 пунктында каралган документларны 10 эш көне эчендә карый. Комиссиянең бер мәртәбә бирелә торган матди түләү бирү турындагы йә бирүдән баш тарту турындагы карарны беркетмә белән рәсмиләштерелә.

8. Бер тапкыр бирелә торган матди түләү алучыга түләүне бирүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында каралган документларны тапшырмау (яки тулы күләмдә тапшырмау);

2) бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләүне алуга мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау фактын ачыклау.

9. Бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне алуга дәгъва кылучыларны сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты сайтында яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне бүлү комиссиясе утырышын үткәргәннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштыру юлы белән җәмәгатьчелеккә җиткерелә.

10. Комиссия утырышы беркетмәсе Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Башкарма комитетына комиссия утырышын уздыру датасыннан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

11. Комиссиянең барлык әгъзалары имзалаган беркетмәне алганнан соң 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләү алучы һәм түләү күләме күрсәтелгән карар кабул итә.

12. Бер мәртәбә бирелә торган матди түләү бирү өчен нигез булып Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты һәм бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне алучы арасында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә төзелгән килешү тора. Килешү карар имзаланганнан соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча төзелә.

13. Бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне алучының банк счетына килешү төзелгәннән соң акча күчерү 60 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

14. Матди (акчалата) түләүне алучы бер мәртәбә матди түләү алу турында төзелгән килешү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының гомуми белем бирү оешмасында бер мәртәбә матди түләү алганнан соң кимендә 5 ел эшләргә тиеш.

15. Матди (акчалата) түләүне алучының гаебе белән шартнамә өзгәндә бирелгән түләү суммасы законнар нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш. Матди (акчалата) түләүне алучы гаебе белән килешүне вакытыннан алда өзү өчен түбәндәгеләр нигез була:

- матди (акчалата) түләү алучы тарафыннан үзе турында алдан ук дөрес булмаган белешмәләр бирүе;

- матди (акчалата) түләү алучының әлеге нигезләмәдә һәм төзелгән килешүдә каралган шартларны үтәмәве;

- эш бирүчегә түләү алучының хезмәт эшчәнлеге турында канәгатьләнерлек булмаган объектив характеристика, характеристикада булган фактлар документлар белән раслана.

16. Килешүнең гамәлдә булуын җитди сәбәп белән туктатып торганда, гомуми белем бирү оешмасында түләүне алучының эше килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору срогы озайтыла.

Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору өчен түбәндәгеләр нигез була:

-тиешле документлар (табиб комиссиясе белешмәсе) белән расланган эш бирүчедә вакытлыча хезмәт эшчәнлегенә комачаулый торган түләү алучының озак вакытлы авыруы (ярты елдан артык вакыт);

- матди (акчалата) түләү алучының балаларының (якын туганнарының) озак вакытлы авыруы (ярты елдан артык срокка), эш бирүченең хезмәт эшчәнлегенә вакытлыча комачаулый, дәвалаучы табибның тиешле белешмәсе белән расланa;

- тиешле документлар белән расланган йөклелек, бала табу, бала карау буенча отпусклар;

- матди (акчалата) түләү алучыны Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хәрби хезмәткә чакыру.

17. Әлеге нигезләмәнең 15 пунктында каралган нигезләр барлыкка килгәндә, эш бирүче 14 календарь көн эчендә комиссия секретарена килешүнең гамәлдә булуын өзү кирәклеге турында язма хәбәрнамәләр җибәрә, килешүне өзү нигезләрен раслый торган документлар да теркәлә.

Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору турында язма хәбәрнамәләр алынганнан соң 7 эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия беркетмә белән рәсмиләштерелә торган килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар кабул итә. Комиссия утырышы беркетмәсе Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Башкарма комитетына комиссия утырышын уздыру датасыннан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

18. Әлеге нигезләмәнең 16 пунктында каралган нигезләр булганда, түләүне алучы нигезләр барлыкка килгәннән соң 14 календарь көн эчендә комиссия секретарена килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору турында язма хәбәрнамәләр һәм килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору өчен нигезләрне раслый торган документлар җибәрә.

Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору турында язма хәбәрнамәләр алынганнан соң 7 эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия беркетмә белән рәсмиләштерелә торган килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар кабул итә. Комиссия утырышы беркетмәсе Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Башкарма комитетына комиссия утырышын уздыру датасыннан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 3 мартындагы
424 няе номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләүне бүлү комиссиясе турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне бүлү комиссиясе (алга таба - комиссия) бер мәртәбә бирелә торган матди түләүне бүлү турында объектив карар кабул итү максатларында төзелде.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә әлеге нигезләмәгә һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди түләү бирү турындагы нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең сан һәм персональ составы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

4. Комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) комиссия утырышларын әзерләүдә катнашырга;

2) комиссия рәисенә утырышны кичектерү турында тәкъдимнәр кертергә;

3) комиссия утырышында катнашырга;

4) комиссия тарафыннан карауга чыгарылган мәсьәләләр турында фикер алышуда катнашырга;

5) Тикшерүгә чыгарылган мәсьәлә буенча фикерне бәян итәргә.

5. Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссия утырышында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

2) комиссия утырышларында кабул ителгән карарларга кул куя.

6. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук комиссия рәисе вазифаларын ул булмаганда башкара.

7. Комиссия секретаре комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссия түбәндәге эшләрне башкара;

2) комиссия утырышларына эш материалларын әзерләүне оештыра;

3) комиссия әгъзаларына утырышның урыны, вакыты, уздырылуы һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә материаллар белән тәэмин итә;

4) комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара.

8. Комиссия утырышында әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары утырышта шәхсән үзләре катнаша. Эшче төркем әгъзасы утырышта булмаган очракта, ул карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә тәкъдим итәргә хокуклы.

9. Комиссия карарлары тапшырылган документларны карау һәм аларның түләү бирү нигезләмәсе таләпләренә туры килү нәтиҗәләре буенча ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен комиссия әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыграгы тавыш биргән булса, кабул ителгән дип санала.

10. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

11. Комиссия карары комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләүне бүлү комиссиясе составы**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе - комиссия рәисе.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары - рәис урынбасары.

3. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең кадрлар бүлеге белгече - комиссия секретаре.

4. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе - комиссия әгъзасы (килешү буенча).

5. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы - комиссия әгъзасы (килешү буенча).

6. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы - комиссия әгъзасы.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 3 мартындагы
424 нчы номерлы
карарына 3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди (акчалата) түләү бирүгә**
**КИЛЕШҮ формасы**

РТ, АМР, Алабуга шәһәре 20____ елның "___"__________

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә эш итүче _____________________ Башкарма комитеты, алга таба «Яшь педагог» дип аталачак (алга таба «Эш бирүче» дип аталачак) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты *исеменнән, бер яктан*, _________________________________ йөзендә, икенче яктан, _____________________________________________ икенче яктан, алга таба, яклар дип аталып, түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр.

1. Килешү предметы

1.1. Килешүнең предметы булып эш бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче яшь педагогларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән тиешле елда күрсәтелгән максатларга каралган Алабуга муниципаль районы бюджеты акчалары чикләрендә ярдәм күрсәтү тора.

2. Якларның йөкләмәләре

2.1. Эш бирүченең йөкләмәләре:

2.1.1. Эш бирүче яшь педагогка бер тапкыр бирелә торган матди түләүне түләүсез нигездә 400 000 (дүрт йөз мең) сум күләмендә түли.

2.2. Яшь педагогның йөкләмәләре:

2.2.1. .Яшь педагог үз ягыннан "_____" __________________________________________ хезмәт шартнамәсе шартларын башкарырга тиеш, ул ________________________________________________
(оешманың атамасы)
әлеге килешү төзелгәннән соң 5 ел дәвамында ________________________________ вазифасында эшләргә, учреждениенең эчке тәртип кагыйдәләре, вазыйфаи инструкция белән билгеләнгән үз бурычларын намус белән үтәргә.

2.2.2. Хезмәт шартнамәсе үз инициативасы белән өзелгән очракта (тиешле документлар белән расланган медицина күрсәткечләре буенча шартнамәнең өзелү сәбәпләреннән тыш) яшь педагог эш бирүчегә бер мәртәбә бирелә торган матди ярдәм күрсәтү суммасын учреждениедән эштән азат итү белән бер үк вакытта тулы күләмдә кайтарырга йөкләмә ала.

## 3. КИЛЕШҮНЕ ҮЗГӘРТҮ ҺӘМ ӨЗҮ

3.1. Килешү шартларын үзгәртү Яклар килешүе буенча гына мөмкин.

3.2. Түләү алучының гаебе белән килешү өзелгәндә бирелгән түләү суммасы законнар нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш. Түләү алучы гаебе белән килешүне вакытыннан алда өзү өчен түбәндәгеләр нигез була:

- түләү алучының тарафыннан үзе турында алдан ук дөрес булмаган белешмәләр бирүе;

- түләү алучының Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче һәм килешү белән төзелгән яшь педагогларга бер мәртәбә бирелә торган матди түләү бирү турындагы нигезләмәдә каралган шартларны үтәмәве;

- эш бирүчегә түләү алучының хезмәт эшчәнлеге турында канәгатьләнерлек булмаган объектив характеристика, характеристикада булган фактлар документлар белән раслана.

3.3. Килешүнең гамәлдә булуын җитди сәбәп белән туктатып торганда, гомуми белем бирү оешмасында түләүне алучының эше килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору срогы озайтыла. Килешүнең гамәлдә булуын туктатып тору өчен түбәндәгеләр нигез була:

- тиешле документлар (табиб комиссиясе белешмәсе) белән расланган эш бирүчедә вакытлыча хезмәт эшчәнлегенә комачаулый торган түләү алучының озак вакытлы авыруы (ярты елдан артык вакыт);

- түләү алучының балаларының (якын туганнарының) озак вакытлы авыруы (ярты елдан артык срокка), эш бирүченең хезмәт эшчәнлегенә вакытлыча комачаулый, дәвалаучы табибның тиешле белешмәсе белән раслана;

- тиешле документлар белән расланган йөклелек, бала табу, бала карау буенча отпусклар;

- түләү алучыны Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хәрби хезмәткә чакыру.

## 4. Килешүнең гамәлдә булу срогы

4.1. Әлеге килешү аңа кул куйган вакыттан алып Яклар тарафыннан үз йөкләмәләрен тулысынча үтәүгә кадәр гамәлдә була.

## 5. Башка шартлар

5.1. Әлеге килешүдә каралмаган башка нәрсәләрдә Яклар гамәлдәге законнар белән җитәкчелек итә.

5.2. Әлеге килешү буенча бәхәсләр законда билгеләнгән тәртиптә карала.

| **Заказ бирүче** | **Эш бирүче** | **Яшь педагог** |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты<br>Урнашу урыны 423600, Республика Татарстан,Алабуга шәһ., Мир пр., 12 й.<br>ИНН 1646018237<br>Исәпкә кую сәбәбе коды 164601001<br>БИК 019205400<br>р/с 032316493260001100<br>Казан ш. ТР НБ бүлеге Россия/УФК Татарстан Республикасы буенча Казан ш.<br><br>Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе<br><br>җитәкче/Фамилиясе, исеме, атасының исеме<br>Мөһер урыны | Оешманың исеме<br>Юридик адрес<br>Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН)<br>Исәпкә кую сәбәбе коды 1<br>Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН)<br>Банк бүлекчәсе<br>Икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД)<br>Банкның тәңгәлләштерү коды (БКК)<br>Исәп/хисап<br>счеты:______________________________________________________________<br>__________<br>корреспондент счеты ____________________________,<br><br>Директор<br><br>Директорның__________________/Фамилиясе, исеме, атасының исеме<br>Мөһер урыны | Фамилиясе, исеме, атасының исеме<br>Туу датасы<br>Муниципаль программа<br>Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН)<br>Яшәү адресы<br>Элемтә өчен телефон номеры |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН